**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңа Сала авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2020 елның 15 июне** **№ 151**

**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңа Сала авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңа Сала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 16 статьясына нигезендә , Кама Тамагы муниципаль районының Яңа Сала авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңа Сала авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
ТР, Кама Тамагы районы, Олы Яңасала авылы, Үзәк ур., 1;
ТР, Кама Тамагы районы, Шәпкә авылы, Клуб ур., 14
3. Әлеге карарны “Идел таңнары” газетасында кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районы Яңа Сала**
**авыл җирлеге башлыгы,**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районы**
**Яңа сала авыл җирлеге Советы рәисе** **И.Х. Шиһабеев**